СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*28 август, 1998 ел.*
*ҖОМГА*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 98 (8255)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘ - АВЫЛ ТЕМАСЫ

***25нче августта район хакимиятенең конференц залында район активы катнашында узган киңәшмә нигездә авыл хуҗалыгында көзге эшләрнең барышы турында сөйләшүгә багышланган иде.***

Анда төп чыгышны район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин һәм хакимият башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев ясадылар. Сөйләшү темасы бер иде: кыр эшләре барышын тизләтү. Киңәшмә көненә сабан культураларының бары 47 проценты суктырылган, эш шундый темплар белән барса, уракны тәмамлау өчен тагын 1 ай вакыт кирәк булачак. Шуңа киңәшмәдә комбайннарны тәүлек әйләнәсенә эшләтү зарурлыгы кабыргасы белән куелды. Ашлык җыю белән беррәттән, товар кредитын каплау буенча эшнең дә канәгатьләнмәслек баруы билгеләнде, кредит түләнмәгән очракта авыл хуҗалыгының авыр хәлдә калачагы тагын бер кат ассызыкланды. Киңәшмәдә уҗым культуралары чәчүне 1 сентябрьгә тәгәлләү бурычы куелды, берочтан аны технологик таләпләр нигезендә, ашлама белән чәчү, эшне ике сменада оештыру шарт итеп куелды. Әлегә "Чулпан" һәм "Заветы Ильича" КХАларында гына бу эш ике сменада алып барыла. Бу эшләр белән бергә туңга сөрүдә техниканы нәтиҗәле файдалану, чөгендер техникасын әзерләүне дә онытмаска әйтелде. Соңгысы әлегә куркыныч астында: 111 чөгендер казыту комбайнының бары 22се генә төзек, яфрак урдыру техникасы да шуннан алын түгел.

Иптәш Сибагатуллин җәмәгать малларына силос салуны тулы куәтенә алып бару, дуңгызлар өчен катнаш силос салу зарурлыгына басым ясады, сөтчелектә эшләрнең торышына канәгатьсезлек белдерде. Шунда ук мөгезле эре яшь терлекләрне лагерьдан кайтару кирәклеге әйтелде.

Киңәшмәдә Пенсия фондына кертемнәр хакында җитди сүз булды. Һәр тармакта ныклы экономия, чыгымнарны киметү, ахыр нәтиҗәгә эшләү - бүгенге көннең төп таләбе шундый, диде Фатих Сәүбәнович. Ике оратордан тыш, бу темага хакимият башлыгы аппараты җитәкчесе Ф.Р. Ногъманова һәм район прокуроры А.П.Евграфов та чыгышларында зур урын бирделәр. Пенсия фондына кертемнәр күчерүнең начар баруын, шуның белән пенсия түләүнең авыраюын әйтеп, өлкәннәр язмышы өчен һәр җитәкченең шәхси җаваплылыкта булуына кабат - кабат басым ясадылар.

Иптәш Евграфов шулай ук юл - транспорт хәрәкәтенең артуы, ГИБДД, "Гостехнадзор" инспекциясе һәм хуҗалык җитәкчеләренең бу юнәлештә тиешенчә эшләмәүләрен ассызыклады, урак чорында халык милкен саклауда уяу булырга чакырды.

Киңәшмәдә агымдагы мәсьәләләр дә каралды.

## РӘХМӘТ ХАТЫ

***Хөрмәтле ФӘТИХ СӘҮБӘНОВИЧ!***

Татарстан Республикасы Мәгариф Министрлыгы Сезгә мәгариф үсешенә керткән зур өлешегез өчен ихлас рәхмәтен белдерә.

Сезнең инициативагыз һәм сүзегездә нык тору, оештыру сәләтегез аркасында мәгариф учреждениеләренең материаль - техник базасы елдан - ел ныгый, педагогларның эше һәм ялы өчен, балаларны укыту һәм тәрбияләү өчен шартлар яхшыра.

Мәгариф проблемаларына тирән уйланылган карашыгыз һәм игътибарыгыз Ватаныбызның чәчәк атуына ярдәм итә, чөнки Татарстан Республикасының киләчәге яшь буынның әхлак һәм физик саулыгы, аның белеме һәм һөнәри дәрәҗәсе белән билгеләнә.

Сезнең җаваплы һәм катлаулы эшегез киләчәктә дә Татарстан халыклары прогрессы хакына уңышлы һәм нәтиҗәле булсын.

Алдагы көннәрдә дә хезмәттәшлекне дәвам итәрбез дип ышаныч белдерәбез. Сезгә нык сәламәтлек, бетмәс - төкәнмәс дәрт, иминлек, бәхет һәм һәр башлаган эшегезгә уңыш телим.

**Министр**
**Ф.Ф.ХАРИСОВ.**

## Минтимер Шәймиев:
## «РЕФОРМАЛАР ЯЗМЫШЫН ИГЕНЧЕДӘН БАШКА ХӘЛ ИТЕП БУЛМЫЙ»

***"Сөрү җирләренең шактый өлешен көйдереп алган тиңдәшсез корылыкка карамастан, мин ышанам, Татарстан икмәкле дә, терлекләр өчен азыклы да булыр". Республика Президенты Минтимер Шәймиев ИТАР - ТАСС хәбәрчесенә әнә шулай дип белдерде.***

- Кыр хезмәтчәннәре быелгы уңыш өчен зур тырышлык һәм осталыкларын салдылар. Ләкин, кызганычка каршы, корылык хөкем сөрү сәбәпле, нәтиҗә куелган хезмәткә тәңгәл булып чыкмады, дип сөйли Президент. Мәсәлән, Нурлат һәм Тәтеш районнары язгы чәчүне беренчеләрдән булып башладылар һәм беренче булып тәгәлләделәр. Ләкин уңышны аз алалар. Быел, игенчелек законнарына каршы килеп, чәчүне соңрак срокларда үткәрүчеләр отты. Яздан ук явым - төшем күләме 4 - 6 миллиметрдан артмаган районнар бар. Ә туфракта температура күп атналар буена 60 градуска җитте. Белгечләрнең исәпләвенчә, 790 мең гектар чәчү мәйданы зыян күрде. Болар нигездә сабан ашлыгы - бодай, борчак, арпа һәм терлек азыгы культуралары. Матди зыян бер миллиард сумнан (деноминацияләнгән) ким түгел.

Табигый афәт, лакмуслы кәгазь кебек, кемнең ничек эшләгәнлеген ачык күрсәтте, дип дәвам итә Президент. Ашлыкның контроль чыгышы гектардан 30ар центнерга җиткән җирләр бар, ә күрше басуда 10 центнерга да тулмый. Күпчелек хуҗалыкларда игенчеләр агротехника культурасын сизелерлек дәрәҗәдә күтәрделәр, шулай булмаса, бөтен уңышның көеп бетү куркынычы бар иде.

Без моңа әзлекле төстә, 1992 елдан бирле килдек. Реформалар башланган чак. Нәкъ менә шул вакытта илдә: "Агропром - кара ярык ул, аңа средстволар тотуның мәгънәсе юк", дигәнрәк төшенчә кулланыла иде. Без исә андый фикерләрне кире кактык. Татарстанда агрокомплекс иң өстенлекле юнәлешләрнең берсе итеп куелды. Ягъни авылга һәрвакыт беренче чиратта игътибар бирелде. Техника сатып алуга күп средстволар бүленде, ашламалар бәясенең яртысына дәүләт түли. Дәүләт шулай ук югары сортлы орлыклар, үсемлекләрне саклау средстволары, алдынгы агротехника буенча фәнни эшләнмәләр белән ярдәм итә. Күп хуҗалыкларда быел ашлыкны ерак элеваторларга - 100 - 150шәр километрга ташу проблемасы килеп туды. Шунлыктан хөкүмәт бу чыгымнарны үз өстенә алды.

Әле нибары биш - алты ел элек республикада 3,8 миллион тонна тулай җыем да рекордлы булып санала иде. Хәзер сөрү җирләре шактый кыскаруга карамастан, ашлык җитештерү бер ярым тапкыр артты.

Элегрәк, без яши торган географик киңлектә ипи пешерерлек бодай үстерү мөмкин түгел, дигән фикер алга сөрелә иде. Ел саен, шактый валюта средстволары тотып, чит илләрдән 400 - 500 мең тонна бодай сатып ала идек. Моннан биш ел элек без азык - төлек бодаен игү буенча комплекслы программа эшләдек. Яңа чәчүлек орлык булдыру өстенә тырышып эшләү, туфракта дымны саклый торган технология һәм техника куллану, ашламаларны фән кушканча кертү, чәчү срокларын саклау - болар бар да уңышка китерде. Кырларыбызда беренче тапкыр җилемсәгә бай бодай ала башладык. 1995 елда 400 мең тонна, узган ел 700 мең тонна азык - төлек бодае сатып алдык.

Быел товар кредиты буенча исәп - хисап өчен хуҗалыклар 480 мең тонна өченче класслы бодай сатарга тиешләр. Аны хәзерли алуыбызга ышанам мин. Без ел башында районнар белән төзелгән договорларда билгеләнгән ныклы бәяләрдән чыгып эш итәбез. Бүген инде безгә БДБ республикаларыннан түбәнрәк бәягә алырга тәкъдим итсәләр дә, үз позициябездән чигенмәскә исәп.

Базарда урын яулау теләге безгә аңлашыла. Ләкин без илебез товар җитештерүчесенә булышу - бүгенге реформаларның нигезе, дип саныйбыз. Дөньяда үз товар җитештерүчесен якламаган берәр илне табып карагыз сез. Бүген базар өчен көрәшәләр генә түгел, ә сугышалар. Кызганычка каршы, илдә товар җитештерүчене яклау ысулы үз вакытында эшләнмәде, бүген шуның зыянын күрәбез. Грузия чигендә шикле спирт төялгән кәрванның бөялеп торуын телевизордан күргәнсездер. Аракы монополиясенә дәүләт катышуын көчәйтеп, Россия хөкүмәте дөрес эшләде. Һәркайсыбыз илдәге товар җитештерүчене яклый башламаса, икътисадны савыктырып булмаячак.

**(Ахыры 2 нче биттә).**

## ПРОБЛЕМАЛАР КҮП ҺӘМ БАРЫСЫ ДА БИК МӨҺИМ

### *Укытучыларның август киңәшмәсендә*



***Г.Г.Габдуллин белән килеп, укытучылар тарафыннан күтеп алынган бу мәртәбәле бәйрәмдә катнашуы аның дәрәҗәсен тагын да арттырып җибәрде. Инде килеп, киңәшмәдә мәгариф өлкәсен ярдәменнән ташламыйча яшәтүче район хакимияте башлыгы, халык депутатларының берләштерелгән Советы рәисе Ф.С.Сибагатуллинның да катнашуы, алай гына да түгел, залда утыручы һәр кешенең йөрәк түренә барып җитәрлек итеп сөйләве дә күңелләргә, кем әйтмешли, сары май булып ятты.***

- Киләчәгебез мәктәп, димәк ки, сез - укытучылар кулында. Киләчәк кешесенең нинди булып формалашуы да сезгә бәйләнгән,- диде ул кереш чыгышында. - Укытучылар армиясеннән дә белемлерәк, компетентлырак коллектив юк районда.

*(Ахыры 3нче биттә).*

***Киңәшле эш таркалмас дип, ел да август башында, яңа уку елы башланыр алдыннан җыелышып киңәш - уңаш тотучы район мәгариф хезмәткәрләренең быелгы киңәшмәсе аеруча үзенчәлекле булды. Моңарчы массакүләм мәгълүмат чаралары аркылы гына танып белгән Мәгариф министрын үз күзләре белән күреп, аның акыллы, төпле чыгышларын тыңлау бәхетенә ирештеләр алар быел. Республика Мәгариф министры Фарис Фахразиевич Харисов Нурлатка район педагогларының зур армиясе белән очрашуга үзе генә түгел, районның мәгариф тармагы тормышында әһәмиятле роль уйнаучы икенче бер шәхес - район белем бирү системасына инновацион формалар кертү буенча фәнни җитәкче, Казан дәүләт педагогия университеты кафедра мөдире, педагогика фәннәре докторы, профессор***



***Рәсемнәрдә: Мәгариф министры Ф.Ф.Харисов трибуна артында; район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин Н.Х.Абдуллинны котлый.***

# «РЕФОРМАЛАР ЯЗМЫШЫН ИГЕНЧЕДӘН БАШКА ХӘЛ ИТЕП БУЛМЫЙ»

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә).**

Яки менә кыр һәм ферма продукциясе сатыла торган шәһәр базарларын алыйк. Прокуратура мәгълүматларына караганда, кайбер базарларда ай саен 100 - 800 деноминацияләнгән сум акча криминаль структуралар кулына эләгә. Пенсияләр, стипендияләр, укытучылар һәм табибларга эш хакы түләү өчен бюджетка бик тә кирәкле акчалар әнә кая китә!

Иң куркынычы шул, криминаль структуралар базар администрацияләренә үтеп керәләр, ә болары үз чиратында, касса аппаратлары куллануга ныклы контрольгә каршы чыгалар. Республика Прокуратурасы, Эчке эшләр министрлыгы, Дәүләт иминлеге комитеты, Салым хезмәтләре бергәләп товар җитештерүчене яклау, базарларда сәүдәне оештыруга ныклы контроль булдыру буенча комплекслы программа эшләделәр. Сәүдә керемнәре оешкан төркемнәр кесәсенә түгел, ә Салым хезмәтләре кассасына керергә тиеш.

Шулай итеп, Минтимер Шәймиев сүзләре белән әйтсәк, бүген ашлык өчен көрәш басудан базарга кадәр барып тоташа. Әмма Татарстанда игенченең ышанычлы хокукый базасы булдырыла - шушы көннәрдә республика Дәүләт Советы Президент искәрмәләреннән соң Җир кодексын кабул итте. Анда, Саратов өлкәсе үрнәгендә, җирне сату - сатып алу каралган.

- Авылдагы яңалыкларга, радикаль икътисадый һәм социаль реформаларга керешкәндә без декларацияләрдән чыгып эш итмәдек,- дип дәвам итә Президент. - Ә, беренчедән, крестьяннарның тормыш тәҗрибәсеннән чыгып фикер йөрттек, икенчедән, бөтенесен ирексездән түгел, ә ихтыяри нигездә эшләдек. Авыл кешесенә нәрсә мөһим? Вакыйгаларның асылына төшенү мөһим. Акыл иясе Конфуций болай дип өйрәткән: "Һәр елны халыкны җыеп сөйләшегез һәм аңа үз вазифаларын аңлатыгыз. Әгәр гади халык үзенең нәрсә эшләргә тиешлеген белмичә, тиешле нәрсәләрне үтәмәсә, ул гаеплемени аңа?" Мәгълүм факт: әгәр крестьян, үзе ышанмаса, берни дә эшләмәячәк. Нинди генә режимнар китереп кысмады инде аны! Әле җирен кистеләр һәм тартып алдылар, әле шәхси хуҗалыклардагы терлекләрнең баш санын кыскарттылар; югарыдан төрле регламентлар, тыюлар җиткерелде; салымнар белән интектерделәр.

Хәзер без аны җирнең хуҗасы итәбез. Татарстан Конституциясе буенча, ә хәзер инде Җир кодексы буенча да җир хосусый милектә була ала, сату - сатып алу темасына әйләнә ала. Җир кодексын гамәлгә ашыруга Татарстан барлык төбәкләргә караганда да яхшырак якын килде. Республикадагы бөтен җирнең - 68 мең квадрат километрлы җирнең - тулы характеристикасын булдыру өчен, аның ничек урнашуын һәм кем кулында булуын учетка алу өчен бик тә зур күләмле эш башкарырга кирәк. Без моны күп еллар буена алдан аз - азлап эшли башлыдык. Хәзерге курс буенча моңа ел саен 50 миллион сум акча тотылды. Җирне бәяләү һәм учетка алуны, эшләрнең бөтен комплексын Россиядә беренче тапкыр компьютерлаштыру нигезендә алып барабыз.

Татарстан Кодексының үзенчәлеге шунда, дип саный Президент, бу документ җирне чит ил кешеләренә дә сатарга рөхсәт итә. "Россиядә мондый хәл юк, булырмы икән - белмим". Ләкин чит ил кешесенә дәүләт фондындагы җир генә сатыла ала, ә ул безнең республикада 1 миллион гектарга якын. Башкача әйткәндә, республиканың махсус дәүләт органы теге яки бу инвесторга җирне сатаргамы - юкмы икәнлеген җентекләп карый. Өстәвенә, җир авыл хуҗалыгы максатларында файдалану шарты белән сатыла.

Оппозициядә торучылар "кызыл әтәчләр" белән, ызаннарда таяклар тотып кыйнашулар белән куркыталар, җирне милек итеп бирүне Ватанны сату белән чагыштыралар. М.Шәймиев моны дөрес түгел дип саный. Татарстанда сөрү җирләренең өчтән ике өлешен җир пайлары сыйфатында бушлай алучы халык, милекчегә әверелеп, үзенең конституцион хокукларын гамәлгә ашыра ала. Ә Конституциядә: җир һәм җир асты байлыклары - республика халкы мөлкәте, дип язылган. Халыкның үз мөлкәте - җире, күчемсез милке булганда гына җәмгыять чын мәгънәсендә демократик була ала.

Җирне сату һәм сатып алу хокукыннан куркырга кирәкми, дип ышандыра Минтимер Шәрипович. Хәзер авыл кешесе эш хакы ала алмаудан зарлана. Җир чын мәгънәсендә "эшли" башласа, җирле үзидарә органнары салым сыйфатында акча ала башлаячак, ә ул акча авыл халкының социаль шартларын яхшыртуга, территорияләрне төзекләндерүгә һ.б.ларга тотылачак. Авыл кешесе чит ил кешесеннән дә файда гына күрәчәк: җирнең хуҗасы булган чит ил кешесе үз өлешендә яңа производство корып җибәрәчәк, прогрессив технология кертәчәк, эш урыннары булдырачак, конкурентка сәләтле продукция эшләп чыгара башлаячак.

Җиргә хуҗа булган дәүләт органы кишәрлекләрне барлык теләүчеләргә, шул исәптән чит ил кешеләренә дә сатачак. Мәсәлән, качакларга. Татарстанда алар хәзер йөз меңнән күбрәк. Җир үз кишәрлекләрен киңәйтергә теләүче күп балалы гаиләләргә дә сатылачак. Әлеге дәүләт органы, әгәр теге яки бу урында җирне сатып алучылар булмаса, халыктан да җирне сатып алырга мөмкин.

Хәзерге вакытта республикада җир реформасын тәэмин итү, сыйфатлы яңа базар булдыру буенча инфраструктура эшләнә. Якын арада ике дистәләп закон акты кабул итәргә, җир банклары ачып җибәрергә кирәк.

**Әңгәмәне Николай СОРОКИН алып барды.**
**("Ватаным Татарстан"нан).**

***Авыл яңарыш юлында***

# ДҮРТ КООПЕРАТИВНЫҢ ӨЧ ТАРИХЫ



*Рәсемдә: "Нива" кооперативы механизаторлары Андрей Ефремов һәм Владимир Оренбуров уракта бик тырышып эшлиләр.*

***Дөресен әйтим: авылда хуҗалык итү турында шундый рухланып, канатланып сөйләгәннәрен күптән тыңлаганым юк иде. Күзләрендә тере ялтырау, йөзләрендә иҗат кешеләренә генә хас илһам чагылышы, тавышларында - ышаныч, ныклык ноталары. Һәм иң гаҗәбе - бу кешеләр әллә кайда, тау артында яки аерым шартларда яшәүче бер төбәктә түгел, инде күпләр кул селтәргә, өмет өзәргә өлгергән Елаурда яшиләр. Без инде бу төбәкнең ничәмә - ничә төрле яшәү чорын хәтерлибез: рәисләр дә алышынды, аренда звенолары да төзеп карадылар, ахыр чиктә МСОның ярдәмче хуҗалыгы итеп тә беркеткән иделәр. Әмма хуҗалык таркала торды, әҗәткә бата барды, халыкта яшәү өмете соңгы чаткыга калды...***

***Дигәндә, төгәлрәге, быелның март аенда район җитәкчелеге авылны яшәтү өчен тагын бер омтылыш ясарга булды: кооперативларга бүленеп эшләргә тәкъдим итте. Бу эштә "Илюткино" хуҗалыгында тәҗрибә туплаган, (заманында Елаурда озак еллар агроном булып эшләгән) Владимир Николаевич Сайкин бирегә кайтып бер кооперативны җитәкләргә ризалык бирде, калган җитәкчеләрне сайлау да кыен булмады. Шулай итеп, яз көнне Елаурда 5 кооператив оештырылды: "Нива", "Руслан", "Берлек", "Нур" һәм "Каенлык", соңрак алар бераз үзгәреш кичерделәр. "Нур" "Петровский" итеп үзгәртелде, аның җитәкчесе алышынды - хәзер анда А.Ефимов рәис. "Руслан"га исә "Каенлык"ны да берләштерделәр, җитәкчесе булып Мәҗидулла Хәмидуллин калды. Тигез итеп җирне, терлекләрне, техниканы, эшче кулларны һәм эшләмәүче халыкны (пенсионерлар, хезмәткәрләр) бүлделәр, һәрберсен кооперативка гариза нигезендә кабул иттеләр, килешү төзеделәр һәм... яши башладылар. Оештыру эшләре белән озак маташырга вакытлары булмады: алда язгы чәчү тора иде.***

***Кооперативлар биографиясе шулай башланды. Хәер, бер кечкенә генә детальне өстәргә оныткамын: бу чорга аларның 7,5 млн. (яңа белән!) эчке һәм тышкы бурычлары, өч исән тракторлары һәм 1700 гектар күздән эшкәртелмичә калган сөрү мәйданы бар иде.***

***Ә хәзер кооператив җитәкчеләре алты айлык эш тәҗрибәләрен кайда елмаеп, кайда - әрнеп, кайда - сөенеп бүлешеп утыралар. Сүзләрендә бер фикер бәхәссез ныклык белән сузыла: безгә әллә кайчан шулай яшәргә кирәк булган икән, халык уянды, үземә дип эшли башлады, яшәүгә өмет туды. Дүрт кооперативлы берләшмәнең өч җитәкчесе безне акрынлап үз хуҗалыгы дөньясына алып керделәр.***

***"Нива" кооперативы***

# «КИЛЕР УРЫН ТАПТЫЛАР»

Владимир Николаевич Сайкин ул беренче көннәрне яхшы хәтерли: кооперативта бердәнбер төзек ДТ - 75 тракторы бар иде. Кооператив әгъзалары белән җыелыштылар да киңәшә башладылар: нишләргә? Ничек язгы чәчүне башкарырга? Күздән эшкәртелмәгән җир җәйрәп ята, ә чәчү срогы - ай - һай санаулы.

Уңыш исә үзебез өчен "ничек эшлибез - шулай яшибез".

Шул бер сөйләшү җитте. Металлоломны ташып бетерделәр, кем каян булдыра - запас частьләр тапты, кем күпме түзә - шулкадәр ремонтта эшләде. Язгы чәчүгә... 4 төзек трактор белән керештеләр! Юкса, баланста да ул 2 генә тора иде. Башка кооперативларда да эш шулай оештырылды. Нәтиҗәдә, кооперативлар берлеге язгы чәчүне районда беренчеләрдән булып төгәлләде, кыр эшләренең башка төрләрендә дә башлангыч тәртипне җуймады.

Владимир Николаевич беренче көннән үк авыл кешеләренә җәннәт вәгъдә итмәде. "Акча юк, булмаячак та. Үзебезгә эшләргә өйрәнергә туры киләчәк". Урман хуҗалыгыннан 300 куб. метр урман алдылар, үзләре чистарттылар, кистеләр һәм халыкка кыш чыгарлык утын бирделәр. Авыл халкы сөенеп туя алмады: утынның бәясе хөкүмәтнекеннән 2 тапкырга арзангарак төште. Урман хуҗалыкның вак - төяк ихтыяҗын үтәрлек акча да китерде.

Азык әзерләү кампаниясе башлангач, халыкка печәнен, саламын бүлеп бирделәр. Теге яки бу йомышы төшкән кеше хәзер туп - туры кооперативка килә, болары канәгатьләндерергә, үтәргә тырышалар.

Аның каравы, шул ук кеше кисәтүсез - нисез һәр көнне иртәнге 6дан эш урынына ашыга. Аны чыбыркылыйсы, оялтасы юк. Җае булганда ике эшне дә тарта. Әнә, көзге чәчү чорында 4 кеше - бер тракторчы, бер чәчүче, бер шофер һәм бер заправкалаучы 300 гектарда чәчү үткәрделәр (заправкалаучы төп эшеннән бушауга катоклауга керешә!). Элекке чак булса, бу хезмәтне 10 кеше башкарыр иде, һич ялгансыз! Ә алар әле күршегә дә ярдәм итәргә өлгерәләр. Бер көнне "Берлек"тә чәчү агрегаты ремонтка туктагач, "Нива"лылар барып, 50 гектарда чәчү үткәреп кайттылар. Бушка түгел, әлбәттә, үзара исәп - хисап ясап! Шулай итеп, кооператив 300 гектарда көзге чәчү чәчте. Бу - кооператив чәчәргә тиешле мәйданның 80 проценты. Ходай кушса, күздән аны тукландырып калдырырга, туңга сөрүне тулысынча башкарырга да җайлары бар. Сыйфат та бүтән. Әле кичә генә Геннадий Мензелеев агрегатының туктап торуын күреп, рәис анда ашыккан. Ватылганнармы, дисә - юк икән, ашламалары беткән, менә - менә китерергә тиешләр. Элеккегә чак булса, гектар артыннан куып, ашламасыз гына чәчә тормаслар идеме?

Менә шулай. Игенчеләр кырга ябырылып ятканнар. Кооператив үзен яшәтер өчен үзе үк акча чыганагы эзли. Кыш көнне сатып алып, симертү өчен 50 баш кына булса да мөгезле эре терлек группасы тупларга җыеналар. Умарталык сатып алганнар, киләчәктә умартачылык белән дә шөгыльләнергә җыеналар. Өч берәмлек - баш инженер, кооператив рәисе һәм бухгалтердан торган администрация уйлый, эзли, баш вата. Бар да җиңел генә бармый. Үз расчет счетлары була торып та җәелеп китеп эшли алмыйлар. Кайда барып керсәләр дә - аларны элекке бурычлары көтә. Ә бурычлыны яратмыйлар. Шуңа алар үз кирәк - яракларын үз чыганакларыннан арзангарак хакка табарга тырышалар. Ничек кенә булса да туар көнгә эшләрлек, яшәрлек, кешенең рухын сакларлык хәлне югалтмаска тырышалар. Чөнки бик зур, бик кыйммәтле нәрсә бит ул - халык ышанычы.

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**
**(Ахыры киләсе санда).**

*Укытучыларның август киңәшмәсендә*

# ПРОБЛЕМАЛАР КҮП ҺӘМ БАРЫСЫ ДА БИК МӨҺИМ

*(Ахыры. Башы 1нче биттә).*

Аннан соң район хакиме мәгариф тармагында эшләүчеләрнең бүгенге катлаулы сәяси- икътисадый шартларда да үз бурычларын дөрес аңлап, аны тулысынча үтәүләрен ассызыклады. Аерым алганда, быел 1296 урынлы типовой яңа мәктәп төзелә башлау, берничә мәгариф учреждениеләренең капиталь ремонтлануын, калган барысының да агымдагы төзәтү эшләрен уңышлы үткәреп, уку елына яхшы хәзерлек белән килүен мактап телгә алды. Район җитәкчесенең тулаем мәгариф өлкәсендәге проблемаларны якыннан белүен дә тойдылар укытучылар. Аерым алганда, Фома, Кәкре Атау, Торнояс мәктәпләренә кичектергесез капиталь ремонт таләп ителүе, шәһәр мәктәпләренең, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең кысанлыгы, соңгы елларда җиһаз, каты инвентарь белән начар тәэмин ителүен, мәктәпләрдәге иске компьютерларны яңаларына алыштыруны тизләтү кирәклеген ассызыклады.

Фатих Сәүбәновичны бигрәк тә борчыган икенче бер нәрсә - мәктәп балаларының сәламәтлеге. (Республикабыз Президенты М.Ш. Шәймиев мәгариф җитәкчеләре, шәһәр һәм район хакимиятләре башлыклары, төрле министрлык һәм ведомство җитәкчеләре белән булган очрашуында да бу мәсьәләне иң үзәге итеп күтәргән иде). Балаларның рухи үсеш дәрәҗәсенең күбрәк булуы, аларның байтагының яшьли теге яки бу хроник авырудан иза чигүе, шул сәбәпле хәрби хезмәткә чакырылучы байтак яшьләрнең "брак"ка чыгарылуы турында борчылып сөйләде ул. Иң куркыныч нәрсә - яшьләрнең аңнары формалашканчы ук яшьли алкоголь, наркомания колына әверелүләренә дә битараф кала алмавын белдереп, заманның бу чиренә каршы бергәләп кулга - кул тотынып кискен көрәшкә чыгарга чакырды. Бу җәһәттән, үзе үк байтак гамәли киңәшләр дә тәкъдим итте. Һәм, әйтергә кирәк, ул тулы дәрәҗәдә район мәгариф бүлеге мөдире Г.М.Юнысовның чыгышындагы фактларга да аваздаш иде. Габделгазиз Миннеәхмәтович балаларның сәламәтлеген ныгыту буенча максатчан эш алып баручы коллективларны атап, төп ориентирларны да ачыклады: экологик тәрбия, балаларны хезмәткә өйрәтү аркылы балалар эшчәнлегенең төрле формаларын активлаштырырга ярдәм итүче комплекслы занятиеләр, укыту - тәрбия процессын балаларның акыл һәм физик осталыкларын коррекцияләүгә юнәлдерү, ахыр чиктә үсмерләр арасында авыруларны, балаларның юлларда гарипләнүен профилактикалау буенча мәгариф бүлегенең санэпидкүзәтү үзәге белән берлектә төзелгән комплекслы чараларын тормышка ашыру зур нәрсә булыр иде дип билгеләде. Бу уңайдан, киңәшмәдә трибунадан торып сөйләүчеләр авызыннан ишетелгән фикерләрнең байтагы да бүген үк кулланышка кертелсен иде диясе килә. Югары Нурлат урта мәктәбенең әйдәп баручы укытучысы Г.Г. Мөхәммәтова, мәсәлән, кеше организмы төзелешен өйрәнүче һәм сәламәт яшәү рәвеше булдыруга хезмәт итүче яңа фән - факультатив рәвешендә валеология фәне укыту буенча тәҗрибә уртаклашты. Ритмика, аутоген күнегүләр, бию, актив тәнәфесләр, физкультминутлар, тренинг, сулыш гимнастикасы, суган үстерү, үләннәр җыю, гөлләр үстерү, хәрәкәт, дөрес һәм тулы кыйммәтле туклану, чыныгу - бары уңай эмоцияләр барышына китерүгә хезмәт итүче факторлар турында искиткеч кызыклы итеп сөйләде ул. "Камыр батыр" укыту - тәрбия комплексы директоры урынбасары В.Ш.Мәрдәншина музыкаль тәрбиянең һәрьяктан уңай йогынты ясавын билгеләсә, "Чишмәкәй" мәктәпкәчә гимназия мөдире Г.А. Кореева комплекслы интеграцияләнгән белем бирүнең баланың физик, шулай ук интеллектуаль үсешенә тәэсирен аерым ассызыклады. Һәм бу проблемага шулай дәррәү кубып мөрәҗәгать итү һич тә очраклы түгел. Янә килеп, Габделгазиз Миннеәхмәтович чыгышына мөрәҗәгать итик. Доклад башыннан алып азагына кадәр бер проблема - киләчәк өчен һәрьяктан белемле, гармонияле, һәм тулысынча сау - сәламәт шәхес тәрбияләүгә багышланган иде. Әнә, районда ун меңләп укучының ай саен 6 - 7 меңе мәктәп ашханәләрендә туклана. Күбесе бушлай ашый. Авыл мәктәпләренең шефлары- авыл хуҗалыгы ассоциацияләре, бүген авыр көн күрүләренә карамастан, мәктәпләрне беренчел кирәк азык - төлек белән тәэмин итүне алгы планга куялар. Мәктәпләр үзләре дә ашханәләр өчен җитәрлек күләмдә яшелчә, җиләк - җимеш хәзерләүгә һәрдаим игътибар бирәләр.



*Якушкино урта мәктәбе укытучылары Л.С.Ярмушкина һәм В.А.Питубаева.*



*Залда - игътибар һәм тынлык.*

Милли мәгариф. Киңәшмәдә бу проблема да кабыргасы белән куелды. Габделгазиз Миннеәхмәтович чыгышында китерелгән саннардан күренгәнчә, урта мәктәпләрнең 15, башлангычларның 10, мәктәпкәчә учреждениеләрнең 10сында укыту һәм тәрбияләү татар телендә алып барыла. Шәһәр мәктәпләрендә 16 татар сыйныфы булдырылган. Икенче төрле итеп әйткәндә, район мәктәпләрендә укучы татар балаларының 11 проценты татар телендә белем ала. Нигездә барлык мәктәпләрдә дә дәүләт теле буларак татар теле өйрәнелә. Быелгы уку елында шәһәр мәктәпләрендә 27 татар сыйныфы (418 укучы) оештырылган. Оратор залдагыларны бу юнәлештәге яңалык белән дә таныштырды. Яңа уку елыннан ана теле буларак татар теле укытыла торган аерым мәктәпләрнең 1 - 4 сыйныфларында татар һәм рус телләре мәҗбүри һәм бер дәрәҗәдә өйрәнелә башлый.

Фикер алышуда катнашкан шәһәрнең беренче мәктәбе директорының милли мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ж.Закированың чыгышы исә мәгариф бүлеге мөдиренең чыгышына өстәмә буларак, җирле мисаллар белән дә тулыландырылган иде. Егоркино урта мәктәбе директоры Т.А. Жилина сөйләгән сүзләр исә мәктәп эчендәге контроль темасын кузгатты.

Узган уку елына тулаем анализ, уңышлар һәм хәл итеп җиткерелмәгән проблемалар һ.б. - киңәшмәдә боларның һәркайсы хакында эшлекле, җитди сөйләшү генә булып калмыйча, мәгариф хезмәткәрләре алдына мөһим бурычлар да конкрет итеп куелды: белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең аналитик эшчәнлек культурасын күтәрү, идарә итүнең информацион системасын тәэмин итүне камилләштерү, мәктәп эче контролен көчәйтү, уку планнары һәм программаларын дәүләт стандартын исәпкә алып үтәү, укыту - тәрбия эшендә ахыргы нәтиҗәгә ирешү...

Һәм киләсе уку елының балалар сәламәтлеге турында кайгырту елы дип игълан ителүе уңаеннан конкрет шул мәсьәләгә юнәлдерелгән комплекслы программа да кабул ителде.

Мәртәбәле кунаклар - Ф.Ф.Харисов һәм Г.Г. Габдуллин чыгышларын да зур игътибар һәм канәгатьләнү белән тыңладылар укытучылар. Икенчесе районда ныклы урын алган эксперименталь эшнең беренче нәтиҗәләре турында әйтсә, Министр 12 еллык уку планына күчүгә хәзерлек, уку планындагы үзгәрешләр турында аңлаешлы итеп сөйләде, милли мәгариф проблемаларына киң тукталды, бүгенге катлаулы заманда балалар тәрбияләү кебек четрекле өлкәдә һәрбер укыту - тәрбия учреждениесендә эшне югары дәрәҗәдә оештыру, бу юнәлештә үтемле идеологик ориентирлар билгеләү кирәклегенә игътибар юнәлтте. Балалар сәламәтлеге - бу тема Фарис Фахразиевич чыгышының башыннан азагынача кызыл җеп булып сузылды.

Киңәшмәдә хезмәттә аерым уңышларга ирешкән бер төркем педагогларга Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, район хакимияте, мәгариф бүлеге Мактау кәгазьләре, акчалата бүләкләр тапшырылды. Министрлыкның Мактау хаты белән бүләкләнүчеләр арасында мәгариф тармагы турында һәрдаим кайгыртучанлык күрсәтеп яшәүче районыбыз хакиме Ф.С. Сибагатуллин да бар иде. Бөтен гомерен укыту - тәрбия эшенә биргән, соңгы 16 елын берөзлексез район мәгариф бүлегенә җитәкчелек иткән һәм хәзер район хакимияте башлыгы урынбасары булып эшләүче Н.Х.Абдуллинга 50 еллыгы уңаеннан Министрлыкның Мактау кәгазе һәм район хакимияте исеменнән Мактау кәгазе һәм кыйммәтле бүләк тапшырылды.

Киңәшмәдә шулай ук белем бирү учреждениеләрен яңа уку елына хәзерләү буенча смотр - конкурска йомгак та ясалды.

Соңыннан "Росинка" балалар бакчасы, Зирекле һәм Егоркино урта мәктәпләре коллективлары иҗади отчет тоттылар.

**Р.ГИНЯЕВА.**



*"Алсу" мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе тәрбиячеләре Ф.С.Мөхәммәтова һәм Г.К.Миннеханова.*

*Н.АЗИЗОВ фотолары.*

## УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ХАТЛАРЫ     УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ХАТЛАРЫ

### ЯҢА УКУ ЕЛЫНА ӘЗЕРЛЕК БАРА

# ЗИРЕКЛЕ МӘКТӘБЕ ҺӘРЧАК ӘЗЕР

***Мәктәп белән Фәридә апа Сәгыйрова 1989 елдан бирле идарә итә. Өлкән укытучы. Таләпчән, оста оештыручы, җитәкче. Шулай булмаса, мәктәптә шулкадәр күләмле эшләр башкару өчен көче җитәр идемени. Мин аңардан шул хакта сораштым.***

- Мәктәптә каникул юк инде ул. Ел әйләнәсе эштә. Уку елы тәмамлану белән яңасына әзерлек башлана.

Чыгарылыш имтиханнары бетү белән ял һәм хезмәт лагере оештырдык. Бу лагерь өч сменада, егерме дүртешәр көн эшләде. Менә шул көннән мәктәп тирәсендә кечкенә ремонт эшләре башланып китте дә инде. Балалар бакчада да эшләделәр. Лагерьда кайнар аш белән тәэмин иттеләр. Август аенда аз керемле, күп балалы гаиләләрнең балаларыннан түләүле бригада оештырдык. Алар 167 сум акча алачаклар. Балалар да, ата - аналар да бу лагерьдан бик канәгать.

Еллар авыр булуга карамастан, мәктәп балаларга яңа уку елында белем һәм тәрбия бирергә әзер. Уку әсбаплары белән тәэмин ителгән. Быел мәктәп эчендә җиңелчә генә ремонт эшләре үткәрелде. Инде мәктәпне газлаштыру өчен бар көчебезне куябыз. (Әлегә кадәр мәктәп электр, ут булмаганда мичләр белән җылытылган.- Х.Ә.) Котельнялар төзибез, газ торбалары үткәрәбез. Әле тагын яңа спортзал өлгертеп киләбез.

***- Күрәм, мәктәп бик иске...***

- Әйе, мәктәп 1961нче елдан бирле эшли. Киләчәккә мәктәпне тышларга һәм зурайтырга планлаштырабыз. Быел бу эшне эшлисе иде - барып чыкмады.

***- Ә бу эшләрне башкаруда ярдәмчеләрегез бармы соң, акча белән диюем?***

- Мәктәпне ремонтлауга акча соңгы елларда бөтенләй бүлеп бирелмәде. Төрле юллар белән, үз чыганакларыбыз аша мөмкинлекләрне файдаланабыз. Төрле предприятиеләр зур салымнардан азат ителү өчен ярдәмнәрен күрсәтәләр. Менә шулай көн күрәбез...

***- Димәк, Зирекле мәктәбе 1998 - 99нчы уку елына балаларга төпле белем һәм тәрбия бирергә әзер дияргә урын бар.***

**Х. ӘЛИМОВ.**

### Бер авторыбыз яза

## ТЫНГЫСЫЗ ХЕЗМӘТТӘ

Һәркөн аның киләсен авыл халкы белеп бетергән инде. Иртәнге сәгать 4нче яртыда капка төбенә җигүле ат килеп туктый. Уңган хуҗабикәләр мөлдерәмә тулы чиләкләрен алып, аңа каршы чыгалар.

Асия Хафизуллина инде ничә еллар шушы хезмәттә - индивидуаль сектордан сөт җыя. Тынгысыз ул, үз хезмәтен күңел биреп башкара. Авыл халкы белән уртак тел дә таба белә. Бу хезмәт белән бергә әле ул шикәр чөгендере эшкәртүдә дә катнашты. Кирәк икән - ындыр табагына эшкә дә чакыралар аны. Ә кышын исә савучыларны ял иттерергә фермага килә ул. Һәм, әйтергә кирәк, колхоз производствосының кайсы гына тармагында эшләсә дә, үз эшен һәрвакыт җиренә җиткереп башкара. Ә өендә ул - уңган хуҗабикә. Ире Илһам белән 5 бала тәрбияләп үстерәләр: 3 малай һәм ике кыз. Зур кызлары Энҗе Казан педагогия университетының 4нче курсында укый. Илнур белән Илсур кечкенәдән ат өстендә йөрергә яраттылар һәм быелгы Сабан туеның ат чабышында 1 - 3нче урынпарны яулап, кыйммәтле бүләккә лаек булдылар. Алсу быел 4нче сыйныфка укырга барачак. Ә кечкенә Алмаз балалар бакчасына йөри. Гаилә башлыгы Илһам абый - тәртипле ата. Быел яңа өй җиткезеп керделәр, гөрләтеп өй туе уздырдылар. Яңа өйдә исәнлек һәм тынычлык белән яшәргә язсын сезгә!

## УҢГАН САТУЧЫЛАР

Кычытканлы авылы сатучылары апалы - сеңелле Минзифа Абдрахманова һәм Зөлфа Сәлахова сәүдә системасында күптәннән эшлиләр инде. Тәҗрибәле сатучыларның авыл халкы белән мөнәсәбәтләре дә әйбәт. Кибеттә халыкның тормыш - көнкүреше өчен кирәкле товарлар җитәрлек, нәрсә телисең шул бар. Кибет эче чиста, матур. Һәрбер товар үз урынында, киштәләргә кырт итеп тезеп куелган. Көннеке - көнгә пешкән ипи, батоннар кайтып тора. Акчаң гына булсын. Һәрвакыт ачык йөзле булып, халыкка игелекле хезмәт итегез, хөрмәтле ак халатлы сатучыларыбыз!

**З.ИСМӘГЫЙЛЕВА.**
**Кычытканлы авылы.**

### Укырга чакырабыз

***Хокук һәм идарә, икътисад, гуманитар фәннәр Көнчыгыш институтының Бөгелмәдәге вәкиллеге түбәндәге факультетларга студентлар кабул итә: юридик, финанс - икътисад, тарих - филология, педагогика һәм психология, чит телләр, физкультура һәм спорт, социаль - мәдәни эшләр.***

***Уку читтән торып һәм түләүле. Түләүдә ташламалар бар. Кабул итү имтихансыз, тест нигезендә. Уку беткәч, дәүләти үрнәктәге диплом бирелә. РФның Югары Белем Дәүләт комитеты тарафыннан 24.05.95 елда бирелгән 16 - 227 номерлы лицензия. РФ Гомуми урта белем бирү министрлыгы тарафыннан 17.12.97 елда бирелгән дәүләт аккредитациясе турындагы 25 - 0109 номерлы таныклык .***

Адрес: Бөгелмә шәһәре, Я.Гашек ур., 10. Тел.: 5-39-45, 3- 46-61.

### ОБЪЕКТИВТА - МИЗГЕЛ



***Хөрмәтле укучыларыбыз!***

***Фотоһәвәскәр Радик Рәхимов сурәтенә иң отышлы, иң тапкыр исемне кайсыгыз табар икән? Ул шигъри юллар, мәкальләр белән булса да ярый. Кыскасы, бар фантазиягезне эшкә җигәргә ашыгыгыз, иҗади бәйге игълан итәбез!***

## ХЕЗМӘТЕНӘ КАРАП ХӨРМӘТЕ

Мария Михайловна Мельникова 16 ел инде Чулпан почта бүлекчәсендә хат ташучы булып эшли. Ул авылда бу һөнәргә тугрылыклы булып калган гаиләнең икенче буын вәкиле. Аның әнисе Александра Викторовна да күп еллар почтальон булып эшләде. Лаеклы ялга киткәндә һөнәренең серләре һәм тәҗрибәсе белән бик шатланып кызы белән бүлеште.

Яңа, яшь хат ташучының пөхтәлеген, итәгатьлелеген һәм эшенә зур җаваплылык белән каравын авыл халкы шунда ук сизеп алды. Яңгырда, карда да ул һәркемнең почтасын вакытында китерергә тырыша, гозерләрен игътибар белән тыңлап үтәргә омтыла. Тик шулай да һәрнәрсә чагыштыруда ачыклана, диләр бит. Мариянең хезмәтенә мохтаҗлыкны ул авырып киткәч тагын да ныграк тойдылар. Һәм менә Чулпан урамнарында тагын зур сумкасын күтәргән почтальоныбыз атлаганны күреп, йөзләрдә куаныч балкыды. Авылдашлары аның авыр хезмәтенә рәхмәт белдерәләр һәм исәнлек - саулык телиләр.

**Л.ЕГОРОВА,**
**В.СТЕПАНОВА.**

### РӘХМӘТЕБЕЗ ЧИКСЕЗ

2нче мәктәп - гимназия, редакция, типография администрацияләре һәм коллективларына, реанимация бүлеге табиблары В.Г.Әбделманов, Ә.К.Сафиуллин һәм шәфкать туташларына, күршеләргә, туганнарга, дусларга кадерле **ирем, әтиебез Роберт Зартдин улы АЙЗАТУЛЛИНны** җирләүдә матди һәм мораль ярдәм күрсәткән һәркемгә олы рәхмәтебезне белдерәбез.

**Айзатуллиннар гаиләсе.**


## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА. БЕЛДЕРҮЛӘР.

### САТАБЫЗ

**Чистарту корылмалары ягында гараж.**
Адрес: Гыйматдинов ур., 120 - 21.
***

**1993 елгы, 54 мең км. йөргән, әйбәт хәлдәге, сигнализациясе, "Пионер" магнитофоны булган ВАЗ - 2121 "Нива", бәясе килешү буенча.** Тел.: 2-20-36.
***

**Ашыгыч төстә шәһәр үзәгендә өч бүлмәле фатир (ремонтлыйсы юк), Козлов урамында ике бүлмәле фатир, Чишмә поселогында йорт.** Тел.: 5-17-04, кичке 8дән соң.
***

**Гыйматдинов урамында 11нче иске йорт, участогы, төзү материаллары бар, кыйммәт түгел.**
Тел.: 2-10-84, теләсә кайчан.
***

**Шикәр заводы микрорайонында ике бүлмәле фатир.** Арадашчы тел.: 2-26-99.
***

**Бер ел тотылган, "Сафари" төсендәге ВАЗ - 2106.** Тел.: Нурлатта 2-26-64, Димитровградта 2-24-23.
***

**К.Маркс урамында бер бүлмәле фатир.**
Тел.: 5-13-05, кичке 7дән соң.
***

**"Элемтәче" бакчачылык ширкәтендә дача, кирпеч йорты, коесы бар.** Тел.: 2-12-70 (өй), 2-28-28 (эш).
***

**ВАЗ - 21074.** Тел.: 5-13-57, кичке 5тән соң.
***

**Ашыгыч төстә компьютер.** Тел.: 5-18-07.
***

**Әфган поселогында участок, йорт һәм гараж фундаменты, коесы бар.** Тел.: 5-26-39.
***

**4,20 х 6лы гаражга чана һәм гараж капкасы.**
Тел.: 65-3-48, НУРБ коммутаторы аша.
***

**Ашыгыч төстә 32 кв. м. мәйданлы торак йорт. Газ мунчасы, җиләк- җимеш бакчасы, 11 сутый яшелчә бакчасы бар, газ белән җылытыла.**
Адрес: Островский ур., 39.
***

**Кулланылышта булган тау кәҗәсе тиресеннән тун, чәшке тиресеннән хатын - кызлар баш киеме, кыйммәт түгел.** Тел.: 2-26-10.
***

**Ашыгыч төстә гараж һәм төзелеш материаллары, арзан.** Тел.: 5-27-54.

*Безнең пычкы материаллары - сезнең кышка уңышлы әзерлек*

**Аксубай урман хуҗалыгы пычкы материаллары әзерләп сата. Усак - 1 куб.метры - 252 сум, рәшәткәлек, арболит блоклар. 6 куб.метрдан күбрәккә заказ биргәндә хуҗалык транспорты белән илтеп бирәбез.** Бартер мәсьәләләре, белешмәләр өчен тел.: (244) 2-14-32, 2-11-92 (Аксубай эшчеләр поселогы).

### АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Хосусыйлаштырылган бер бүлмәле фатирны - өстәмә түләп ике бүлмәлегә.** Тел.: 65-7-30.
***

**Көнчыгыш микрорайонында төзелеш материаллары белән төзелеп бетмәгән кирпеч йортны - 2 бүлмәле фатирга яки йортка.** Адрес: Совет ур., 92-8.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

***Фома урта мәктәбе тарафыннан Радик Әнвәр улы Гыйләҗев исеменә бирелгән 033070 номерлы аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип санарга.***
***

**Әйбәт төзүчеләр турында бушлай информация бирәм.** Тел.: 5-16-25 (Нәҗип).

### ХАЛЫК ИГЪТИБАРЫНА!

***Нурлат райпосының азык - төлек комбинаты халыктан төзелеш материалларына алмаштырып ит җыя (шифер, цемент).***

***Һәм сата:***

***1. Шифер - данәсе - 24 сум.***

***2. Цемент - капчыгы - 27 сум.***

***Азык - төлек комбинаты кибетләре пенсионерларга пенсия хисабына ашамлыклар җибәрә. Үзегез белән паспорт һәм пенсия кенәгәсе алып килергә.***

***Комбинат шәһәрнең коммерция структураларын эшлекле хезмәттәшлеккә чакыра.***

Белешмәләр өчен тел.: директор - 2-16-04, бухгалтерия - 2-21-15.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр:Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*ГазетаТатарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясендә офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2488 данә. 3363